

# Яңа елга теләкләр кабул итегез

Кадерле балалар һәм газетаны яратып укып баручы дусларыбыз! Сезне якынлашып килүче Яңа ел бәйрәме белән котлыйбыз.
Бер-берегезгә иң яхшы теләкләр теләгез, бер-берегезне хөрмәт итегез, яратыгыз. Авырмагыз, сәламәт булыгыз! Кыю булыгыз!

Яңа ел - тылсымлы бәйрәм. Ел саен төрле кызыклы могҗизалары белән безне шатландыра. Балалар бакчасында кызлар кар кызлары булалар.Малайлар дҗентельменнар булалар. Бу бәйрәмгә ел буе сагынып көтеп алган Кыш бабай белэн Кар кызы да килә.

Балалар өчен һәрбер яңа ел бәйрәме үзенчәлекле. Чөнки яңа ел бәйрәме - ул бик могҗизалы, тылсымлы бәйрәм. Балалар бу бәйрәмне бик яратып,көтеп алалар. Чөнки кыш бабай аларга бүләкләр алып килә.

Һәр гаилә бу бәйрәмне узләренен гаиләләре белән бергә каршы алалар.Һәр Яңа ел тылсымлы, могҗизалы булып истә кала. Ә иң истә калган Яңа ел бәйрәме ул - балалар бакчасында узганы.

Балалар бакчасына йөручe малайлар һәм кызлар өчен "Яна ел" бик кунелле бәйрәм. Алар Кыш бабай һәм Кар кызы белән күрешәләр. Сабыйлар төрле әкият персонажлары булып узлэре киенэлэр. Киләсе ел символы – яшел елан елы. Юмарт Кыш бабай барлык балаларны бүләкләре – татлы кучтәнәчләре белән шатландыра. Тылсымлы бизәкләргә бай, искиткеч матур Яңа ел бәйрәменең онытылмас мизгелләре нәниләр күңелендә озак сакланачак. Кешеләр Яңа елдан тагын нәрсә көтә? Әлбәттә, шатлык һәм яхшылык. Һәр кеше бары тик яхшылык кына көтә. Бу ел бөтен дөнья өчен авыр булды, шуңа күрә күпмедер дәрәҗәдә без берләшкәнбездер. Яңа елда барыбыз да исән-сау булсак, шатлансак, якыннарыбызны югалтмасак иде һәм без моңа ирешербез дип өметләнәм. Иң мөһиме, сәламәт булыйк. Барысы да исән һәм сәламәт булса, бөтен хыяллар да чынга ашачак.

Киләсе Яңа 2025 нче ел хәерле-рәхмәтле ел булсын! Һәр гаиләгә саулык-сәламәтлек, озын гомер, күңел тынычлыгы, бәрәкәтле тормыш, мул табыннар, дөньялар иминлеге телим. Илебездә, җир шарында сугышлар, табигать гарасатлары, юл афәтләре булмасын, балалар ятим булмасыннар! Илләребез, көннәребез тыныч булсын! Күгебез аяз, өйләребез якты, шатлыклар белән тулсын! Бәхетле булыйк!

# ЧИШМӘ БАШЫ

2 нче сан

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы АПАЗ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесы. Бакчабызның бүгенгесен яктыртучы электрон газета.



## ГАЗЕТАНЫҢ СӘХИФӘЛӘРЕ:

- *Яңа елга теләкләр кабул итегез*
- *Декабрь аена сынамышлар*
- *Мин табышмак әйтәм, син җавабын тап*
- *Әти-әниләргә киңәшләр*

*Баш мөхәррир:бакча мөдире Зайнуллина Индира Тәлгать кызы*
*Мөхәррир урынбасары:тәрбияче Нигъмәтҗанова Лилия Гаптелләхәт кызы*

# Декабрь аена сынамышлар

Декабрьнең егерме бишендә агачларны бәс тотса, алдагы җәй иген уңар.
Декабрьнең утыз берендә төнлә йолдызлар еш күренсә, ашлыклар уңар; шулай ук бәс булса да, ашлыклар уңар.
Декабрьдә кар аз булса, җәй коры килә.
Декабрьдә кара каргалар күренә икән, кыш җылы була.
Карсыз декабрь — коры яз билгесе.
Декабрь башында көчле бураннар, кар яуса, июнь башында яңгырлар була.
Декабрь җилле икән, март җылы була.
Декабрь җылы булса, кыш озакка сузыла, яз салкын була, соңара.
Декабрьгә җир туңса, кар көртләре булса, уңыш уңа.
1 декабрь – әгәр кышның беренче көнендә кара карга күрсәгез, кыш җылы булыр.
2 декабрь – аяз һава кышның салкын килүе турында сөйли. Әгәр бу көнне кар төшсә, гыйнварга кадәр чатнама суыклар көтмәгез.
3 декабрь көнне кар яуса, 3 июньдә көчле яңгыр явар. Әгәр киресенчә булса, җәй иртә килер.
4 декабрь – күктә күп санлы болытлар күренсә, тиздән суытачак. Буран – җылы һәм карсыз кыш башлануы турында сөйли.
5 декабрь көнне көчле суык булса, димәк, тиздән, бураннар башланыр.
6 декабрь көнне кар төшсә, суыклар көтегез. Әгәр бу көнне җепшек икән, Яңа елга кадәр кыш җитмәс.
7 декабрь күктә йолдызлар аермачык янып торса, һава торышы кинәт үзгәрер. Әгәр бу көнне йолдызлар атылса, кышын кар әз явар, ә мартта көчле суыклар килер.
8 декабрь көнне морҗадан чыккан төтенгә игътибар итәләр. Әгәр ул өскә күтәрелсә, тиздән кар явар. Таралып китсә, җилле булыр.
9 декабрь – әгәр бу көнне болытлар җиргә салынып торса, тиздән суыклар җитәр.
10 декабрь көнне эт һәм песиләр үзләрен гадәттәгедән тынычрак тотса, каты суык һәм буран көтегез.
11 декабрь көнне песи тырнаклары белән тырманып йөрсә – суыта. Эт өреп, шыңшый икән – бик көчле суыклар киләчәк.

# Декабрь аена сынамышлар

12 декабрь көнне әзрәк болытлап торса – суыта. Көн томанлы икән – тиздән көчле җил һәм буран булыр.
13 декабрь көнне кар яуса, ул җирдә 110 көн ятар.
14 декабрь – каурый-каурый катламлы болытлар – суыклар җитү турында кисәтә.
15 декабрь көнне яңгыр яуса, ул 40 көн буе дәвам итәр.
16 декабрь көнне балыкчылар яхшы табыш белән кайтса, кыш җылы килер.
17 декабрь көнне агач ботакларында кар ята икән, кыш суык килер.
18 декабрьгә кадәр бер тапкыр да суыклар булмаган икән, димәк тиздән җепшек буран булыр.
19 декабрь песиләр йоклаганда авыз-борынын тәпие белән каплап йокласа, тиздән көчле суыклар килер.
20 декабрь песиләр су эчсә, көчле явым-төшем булыр.
21 декабрь кояш гадәттәгедән иртәрәк чыкса – кар явар.
22 декабрьдә көн аяз булып, кар яуса – җылы кышка ишарә.
23 декабрь дә буран дуласа, көчле суыклар билгесе.
24 декабрь – кошлар түбәннән очса, җилле һава торышына. Көньяктан искән җил көннең җылынуы турында сөйли.
25 декабрь -киләсе елның уңышлы килүен белү өчен, бу көнне чия ботагы кисеп, аны туфрак салынган чүлмәккә утырткannнар. Ул Раштуага яфраклар чыгарса, ел уңышлы килә дип саналган.
26 декабрьдән башлап, 12 көн суык була икән, кыш чатнама суык килер.
27 декабрь – төнлә агачларны бәс сарса, кыш суык килә. Иртәнге чатнама суык тиздән көчле җил һәм буран булачагын искәртә.
28 декабрь көнне җылы була икән, димәк, көчле суыклар кыш азагында гына киләчәк.
29 декабрь – суык һәм өче җил – Раштуа салкыннарының дәвамлы булуы турында сөйли. Болытлы, җилле көн – кинәт җылытуга.
30 декабрь көнне кар яуса, Яңа ел төне суык булыр.
31 декабрь көнне еларга һәм күңелсезләнергә ярамый, юкса, елы буе шундый кәеф озата барачак.

# Мин табышмак әйтәм, син җавабын тап

Елга ул бер генә килә,
Һәркем дә аны көтә.
Тылсымга бай бәйрәм,
Биибез әйлән-бәйлән. (Яңа ел)

Кыш Бабайның оныгы мин,
Аның белән гел бергә.
Тамаша кылып йөрибез
Яңа ел бәйрәмендә. (Карсылу)

Чыршыларга эленәбез,
Сүнәбез дә, янабыз.
Яңа елны яратабыз,
Шуңа балкып торабыз. (Гирлянда)

Бүләкләр төяп килә ул,
Яңа ел саен безгә.
Сагынып көтеп алабыз
Сине без һәммәбездә! (Кыш Бабай)

Мин – Яңа ел символы,
Ямь-яшел күлмәктәнмен.
Уенчыклар әгәр элсәң
Купшыланып китәрмен. (Чыршы)

Көлдерәбез Яңа елда,
Бездән дә юк осталар.
Без көлке сиртмәсеннән,
Артист-юморескалар. (Клоуннар)

Француз исеме белән бәйле
Яңа ел салаты буламын.
Тик Франциядә түгел шул,
Рәсәйдә популярмын! (Оливье салаты)

Кикрикүк диеп кычкырам,
Уянам иртән иртүк.
Йә кем белә, мин ни булам?
Белми тормагыз берүк. (Әтәч)

## *Әти-әниләргә киңәшләр*

*Бала тәрбияләүдә мактау һәм шелтә бик зур роль уйный.*
** Тәрбиядә әти белән әни бер сүздә булып, таләпләр тотрыклы булырга тиеш. Ата-ана кәефе яхшы булганда баласына нәрсә теләсә, шуны эшләргә рөхсәт итә, кәефсез булганда бар нәрсәдән дә тыя икән, бала алга таба бөтенләй тыңламый башларга мөмкин.*
** Бала тәрбияләүдә мактау һәм шелтә бик зур роль уйный. Баланы җәза бирү юлы белән тыңлатырга күнеккән булсагыз, бик нык ялгышасыз. Төрлечә мактау, хуплау юлы белән яхшырак нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин.*
** Ата-ана мәхәббәте баланы киң күңелле, ягымлы, ачык йөзле итә. Шушы мәхәббәт җылысы балада намуслылык, йомшак күңеллелек тәрбияли. Ләкин баланы нык яратам дип, чама хисен югалтмагыз. Югыйсә үз ихтыяҗларын канәгатьләндерүдән баш тарта алмый торган кеше үсәргә мөмкин.*
** Әти-әни – улы һәм кызы өчен камиллек үрнәге. Бала аңына ата һәм аның ролендәге кеше шундый булырга тиеш дип сеңдереп үсә. Балагыз өчен яхшы үрнәк булырга тырышыгыз.*
** Балада эгоизм, ялкаулык, ялганлау кебек начар сыйфатлар күренсә, бу – хәвефле сигнал. Әлеге сыйфатлардан шәфкатьсезлеккә дә ерак түгел. Шәфкатьсезлек кансызлык китереп чыгара. Шуңа күрә балагызның ни белән кызыксынуын, даими шөгыль һәм ял итү урыннарын, кемнәр белән аралашканын белеп торыгыз, укытучылары, иптәшләре белән мөнәсәбәтләреннән хәбәрдар булыгыз.*
** Гаиләдә бергәләп китаплар укыгыз, җырлар һәм музыка тыңлагыз, табигатьтә ял итегез. Шушы татулык һәм бердәмлек аша эстетик кыйммәтләр пәйда була, әхлак тәрбияләнә.*